**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлегенең Бөрбаш торак пунктында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**8 декабрь 2021 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлегенең Бөрбаш торак пунктында халык җыены **карар бирде**:

1. 2022 елда Балтач районы Бөрбаш авылы Бөрбаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булганнарга 900 сум, Бөек Ватан сугышы һәм тыл ветераннары, түбән керемле ялгыз пенсионерлар, 80 яшькә җиткән өлкән пенсионерлар, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләр өчен үзара салым суммасының 90% ы күләмендә ташлама кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- урам яктырткычларын сатып алу һәм монтажлау;
- Бөрбаш авылы торак пунктында территорияне чистарту һәм җыештыру;
- төзекләндерү элементлары белән яр буе территориясен планлаштыру.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Бөрбаш авыл җирлеге Советының мәгълүмәти стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы муниципаль, берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе Р.Р.Галимуллин